**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕШЕМЯКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 56-6-48, факс 56-6-48

# КАРАР

**8 ноябрь 2019 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 21 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Олы Шәмәк авыл Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Олы Шәмәк авыл җирлегенең Олы Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәтеш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесеннән социаль хезмәт алучылар, күпбалалы гаиләләр, балачактан

инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Олы Шәмәк авылы эчендәге Мәктәп ур., Пролетарская ур., Ленин ур., Кутузов ур., Совет ур. юлларны төзекләндерү;
- Олы Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу;
- Олы Шәмәк авылында урам яктырткычлары һәм лампалары сатып алу һәм алыштыру;
- Олы Шәмәк авылына чүп контейнерлары сатып алу;
- Олы Шәмәк авылында карт агачларны кисү ?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы** **А.И. Афанасьев**